КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 30 декабрь г.Казань № 1502

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 10 март, 202 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 13 октябрь, 852 нче; 2013 ел, 18 март, 176 нчы; 2013 ел, 31 октябрь, 829 нчы; 2014 ел, 18 апрель, 257 нче; 2014 ел, 10 июль, 481 нче; 2015 ел, 21 гыйнвар, 25 нче; 2016 ел, 26 июль, 508 нче; 2016 ел, 19 август, 575 нче; 2017 ел, 10 ноябрь, 859 нчы; 2018 ел, 10 май, 340 нчы; 2019 ел, 3 апрель, 262 нче; 2019 ел, 16 июль, 588 нче; 2020 ел, 25 июнь, 525 нче, 2021 ел, 2 март, 110 нчы, 2021 ел, 6 декабрь, 1171 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе аппараты хезмәткәрләренең иң чик санын вазыйфаи окладлар буенча хезмәт өчен түләү фонды 1 455,784 мең сум күләмендә 71 берәмлек күләмендә билгеләргә.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Себер язвасы үләт базларының санитар-яклау зоналары проектларын эшләү максатларында 2022 елда Азнакай муниципаль районы бюджетына финанс белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фондының бюджет ассигнованиеләре булган Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 12 август, 799 нчы карары белән расланган Себер язвасы үләт базларының санитар-яклау зоналары проектларын эшләү максатларында 2022 елда Азнакай муниципаль районы бюджетына финанс белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фондының бюджет ассигнованиеләре булган Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә, 15 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәп, үзгәреш кертергә:

«Ветеринария идарәсенең хисап финанс елында файдаланылмаган башка бюджетара трансфертларга ихтыяҗ булу турындагы карар нигезендә, күрсәтелгән бюджетара трансфертлар акчаларының калдыкларыннан артмаган күләмдә акчалар агымдагы финанс елында башка бюджетара трансфертларны бирү максатларына туры килә торган чыгымнарын финанс белән тәэмин итү өчен бирелгән Азнакай муниципаль районы бюджеты кеременә кире кайтарылырга мөмкин.».

3. Бу карарның гамәле 2022 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин